| | |
|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__26.02.2026__ Казан ш. № _01-05/52-пр_

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 июлендәге 01-05/187-пр номерлы боерыгы белән расланган Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 июлендәге 01-05/187-пр номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2024 елның 7 июнендәге 01-05/156-пр номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп,

аны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

Җитәкче А.Ш. Борһанов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 28 июлендәге 01-05/187-пр номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең _26.02.2026 __ №_01-05/52-пр_ боерыгы редакциясендә)

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең административ процедураларны һәм административ гамәлләрне башкару стандартын, тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр даирәсе

Мөрәҗәгать итүчеләр булып гражданнар, шәхси эшкуарлар, юридик затлар тора.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүчеләр категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Күзәтчелектәге машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының сатылган яки төзекләндерелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавы турындагы ризасызлыкларын карау комиссияләрендә катнашу.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның исеме.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең территориаль бүлекләре (алга таба — Идарә бүлеге) тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

төп нәтиҗәләр, техниканы торгызу чыгымнары, чыгымнарны түләү өчен җаваплы як, җитештерүче предприятие (тәэминатчы) тарафыннан китертелергә тиешле детальләр, төеннәр һәм агрегатлар номенклатурасы булган дәгъваны карау акты (алга таба – дәгъваны карау акты) әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән;

әлеге Регламентка 8 нче кушымта нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында реестр язуын теркәү зарурлыгы юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

Идарә бүлекләренә шәхсән кергәндә яисә почта аша җибәреп;

Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы аша электрон документ рәвешендә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты, әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарә бүлегенә турыдан-туры тапшырылган булса, почта яисә электрон почта аша җибәрелсә, гариза һәм документлар Идарә бүлеге тарафыннан теркәлгән көннән алып тугыз эш көне тәшкил итә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты, әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарә бүлегенә Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша тапшырылган булса, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталында гаризага эш номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән алып тугыз эш көне тәшкил итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

2.5.1. Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җыем Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2023 ел, № 373-5/нпс-2023 карары белән билгеләнгән күләмдә алына һәм Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе сайтында урнаштырылган.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җыем күләме 350 сум тәшкил итә.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә алына торган башка төрле түләүләрне түләү Республика порталыннан яки Бердәм порталдан, Идарәнең рәсми сайтыннан файдаланып гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен җыем күләме турында белешмәләр Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Республика порталында, Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган. Дәүләт пошлинасын күчерү өчен кирәкле реквизитлар белән квитанция бланкын мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Идарә бүлегендә яисә Идарәнең рәсми сайтында алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документка Идарә бүлегенең вазыйфаи затының гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә, Идарә бүлегендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмый.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәүгә алу чоры.

2.7.1. Идарә бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә почта аша, электрон почта аша килгән гариза кергән көненнән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә, эштән тыш вакытта электрон рәвештә килгән гариза икенче эш көненә теркәлә.

2.7.2. Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталында һәм (яки) Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) шәхси кабинетта һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.8. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турында белешмәләр Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://gtn.tatarstan.ru/), шулай ук Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре.

2.9.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу һәм сыйфат күрсәткечләре Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://gtn.tatarstan.ru/), шулай ук Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.10.1. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системалары:

дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы (ГИС ГМП);

тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

2.10.3. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында һәм Бердәм порталда (техник мөмкинлек булган очракта) урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

3) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) Бердәм порталдан (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә, Идарә бүлеге, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую мөмкинлеге;

2) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күмәк гариза җибәрүне күздә тоткан хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткшндә, берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге;

4) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

5) Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында урнаштырылган белешмәләрдән һәм Бердәм порталда (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталында бастырып чыгарылган белешмәләрдән файдаланып, мөрәҗәгать итүче белешмәләрне кертә башлаганчы гаризаның электрон рәвешендәге кырларын тутыру;

6) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

7) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә 3 ай дәвамында.

2.10.4. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.10.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) мөстәкыйль тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка бүлеп, һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителгән һәм нотариусның яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә нотариаль эшләр башкаруга хокукы булган башка вазыйфаи затның тәрҗемәнең дөрес булуы турында таныклый торган язуларына ия булырга тиеш

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте

күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) гариза формасында мәҗбүри кырларның дөрес тутырылмавы;

2) гаризаның һәм электрон формадагы башка документларның законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган булуы;

3) электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

4) әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән бер яисә берничә документның булмавы.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар шушы Регламентның 7 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелә.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү турында мәгълүмат булмау;

2) тапшырылган (алынган) документларда (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

3) үзйөрешле техниканың һәм җайланманың тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәве;

4) эксплуатацияләүнең гарантияле срогы тәмамлану.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) идентификаторларын исәпкә алып, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында мәгълүмат, баш тартуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеге күрсәтелеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр ителә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүче белемнәренең

(күнекмәләренең) Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба – бәяләү процедурасы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Дәүләт хезмәте алгарышлы (проактив) режимда күрсәтелми.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүчене (мөрәҗәгать итүченең вәкилен) профильләштерү мөрәҗәгать итүче тутырган гариза ярдәмендә гамәлгә ашырыла, анда мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүче тутырган гариза нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүче билгеләре күрсәткечләренең тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәркайсы мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырырга тиешле документларның билгеле бер исемлегенә туры килә. Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

Мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге, шулай ук күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны бирү ысуллары әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен билгеләү (идентификацияләү) ысуллары булып түбәндәгеләр тора:

а) Идарә бүлекләрендә – шәхесне таныклаучы документ;

б) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә – Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы, шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза, тикшерү ачкычы сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификациясез электрон имза.

3.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.4. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яки тору урынына (гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен) яки урнашу урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә күрсәтелә.

3.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны теркәү вакыты:

Идарә бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә почта аша, электрон почта аша килгән гариза кергән көненнән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә, эштән тыш вакытта электрон рәвештә килгән гариза икенче эш көненә теркәлә.

Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталында һәм (яки) Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) шәхси кабинетта һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

3.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек.

3.4.1. Гаризаларны җибәрү өчен нигез булып Идарә бүлегендә теркәлгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентка 3 нче кушымта таблицасының 2 бүлегендә күрсәтелгән документларны тапшырмавы тора.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен Идарә бүлегенең вазыйфаи заты «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмат гаризаларын җибәрә:

1) дәүләт хезмәте күрсәткән өчен җыем түләү факты турында белешмәләр – Федераль казначылык идарәсенә җибәрелә;

2) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

3) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә җибәрелә.

Ведомствоара мәгълүмат гаризасын җибәрү срогы дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып бер эш көне тәшкил итә.

3.4.2. Әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда. Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 3.4.1. пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне –дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүче белемнәренең (күнекмәләренең) Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба – бәяләү процедурасы).

3.5.1. Хезмәттән файдалану өчен үзйөрешле техниканы һәм җиһазларны тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килү-килмәвен тикшерү, үзйөрешле техниканың техник торышын идентификацияләү һәм тикшерү процедурасы үткәрелә.

а) бәяләү процедурасының дәвамлылыгы ведомствоара гаризаларга җаваплар кергән көннән алып биш эш көнен тәшкил итә;

б) бәяләү процедурасын үткәрүче субъект – Идарә бүлеге;

в) бәяләү процедурасы объекты – гариза һәм аңа беркетелә торган, мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләрнең дөреслеген, шул исәптән үзйөрешле машинаның һәм җайланмаларның тапшырылган документларда күрсәтелгән белешмәләргә туры килүен раслаучы документлар, шулай ук үзйөрешле машинаның һәм җайланмаларның техник торышын идентификацияләү һәм тикшерү предметы буенча тикшерү.

Комиссия, вазыйфаи зат, Идарә бүлеге, машина хуҗасы һәм тәэмин итүче предприятие (җитештерүче яисә сервис оешмасы) вәкиле составында, гарантияле үзйөрешле техника һәм җайланма тикшерелә.

Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы караганнан соң баш тарту сәбәбе, гаепле як, торгызу өчен кирәкле төеннәр һәм детальләр, торгызу бәясе һәм эшсез торган вакытны исәпкә алып, китерелгән гомуми зыян күләме ачыклана.

Дәгъваны карау нәтиҗәләре буенча Дәгъваны карау акты төзелә.

Идарә бүлегенең вазыйфаи заты үз ягыннан дәгъваны карау актына кул куя.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү.

3.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү ведомствоара гаризаларга җаваплар алган көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә артмаган срокта гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә;

Идарә бүлегенә шәхсән кергәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) мөрәҗәгать итү көнендә бирелә.

Дәгъваны карау акты өч нөсхәдә рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә һәм тәэмин итүче предприятие (җитештерүчегә яисә сервис оешмасы) вәкиленә үзйөрешле техника һәм җайланмаларның эшләмәвен исәпкә алу журналына кул куйдыртып бирелә. Идарә бүлегенең вазыйфаи заты тарафыннан дәгъваны карау актының бер нөсхәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризага теркәп куела.

3.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яисә тору урынына (гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен) яисә урнашу урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә күрсәтелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

шәхсән (мөрәҗәгать итүче Идарә бүлегендә булганда);

мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы аша;

Республика порталы яисә Бердәм портал ярдәмендә (техник мөмкинлек булганда).

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР ИСЕМЛЕГЕ

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен түбәндәге билгеләр һәм кыскартулар кулланыла:

Регламент – «Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу» дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм стандартын билгели торган документ;

дәүләт хезмәте – «Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу» дәүләт хезмәтен күрсәтү;

мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән юридик яисә физик зат, шулай ук шәхси эшкуар буларак теркәлгән затлар;

мөрәҗәгать итүче вәкиле – мөрәҗәгать итүче исеменнән һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат;

Бердәм портал – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

Республика порталы – «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы;

Идарә – Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе;

Идарә бүлеге – Идарәнең Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округындагы территориаль бүлекләре.

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

<table>
<tr><th>№</th><th>Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе</th><th>Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме</th><th>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы</th></tr>
<tr><td>1</td><td rowspan="6">Төп нәтиҗәләр, техниканы торгызу чыгымнары, чыгымнарны түләү өчен җаваплы як, җитештерүче предприятие (тәэминатчы) тарафыннан китертелергә тиешле детальләр, төеннәр һәм агрегатлар номенклатурасы булган дәгъваны карау акты (алга таба – дәгъваны карау акты)</td><td>Гражданнар</td><td>1А</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Юридик затлар</td><td>2А</td></tr>
<tr><td>3</td><td>Шәхси эшкуарлар</td><td>3А</td></tr>
<tr><td>4</td><td>Мөрәҗәгать итүче – гражданин вәкиле</td><td>4А</td></tr>
<tr><td>5</td><td>Мөрәҗәгать итүче – юридик зат вәкиле</td><td>5А</td></tr>
<tr><td>6</td><td>Мөрәҗәгать итүче – шәхси эшкуар вәкиле</td><td>6А</td></tr>
</table>

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Мөрәҗәгать итүче билгесе идентификаторы | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләрен, төркемнән документлар санын расшифровкалау | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| *1.* | *Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшыра торган документлар* | | |
| 1.1. | 1А-6А | гариза | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – оригинал;<br>почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк;<br>гаризаны электрон рәвештә җибәргәндә, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталында гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә бирү зарурлыгыннан тыш, интерактив формада тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. |
| 1.2. | 1А-6А | шәхесне раслаучы документы | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – оригинал;<br>гаризаны Бердәм порталдан (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталыннан файдаланып җибәргәндә мөрәҗәгать итүченең (вәкиленең) шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында исәп язуын раслаганда тикшерелә; |
| 1.3. | 4А, 5А, 6А | мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслый торган документ | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда: документның күчермәсе, бер үк вакытта төп нөсхәсен дә күрсәтеп;<br>почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк;<br>гаризаны Республика порталыннан яисә Бердәм порталдан (техник мөмкинлек булганда) файдаланып җибәргәндә<br>техника хуҗасының вәкиленең вәкаләтләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып төзелгән, машинада укыла торган ышанычнамә белән расланырга мөмкин. |
| 1.4. | 1А-6А | үзйөрешле техника һәм җайланма паспорты (электрон паспорттан өземтә) яисә машинага милек хокукын исбатлый торган башка документлар; | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда: үзйөрешле машина паспорты бирелгән очракта – документның төп нөсхәсе һәм үзйөрешле машинаның электрон паспорты бирелгән очракта – таныклаган күчермәсе;<br>гаризаны Бердәм портал, Республика порталы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан-рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб. ПСМ |
| 1.5. | 1А-6А | гарантия талоны булган сервис кенәгәсе; | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – документның күчермәсе белән төп нөсхәсе; почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк; гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан-рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб. |
| 1.6. | 1А-6А | товар кәгазе; | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – документның күчермәсе; почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк; гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан-рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб. |
| 1.7. | 1А-5А | эксплуатация документлары (эксплуатацияләү буенча куллану кагыйдәләре, эксплуатацияләү буенча кулланма, техник хезмәт күрсәтү буенча кагыйдәләр) | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – документның күчермәсе; почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк; гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан-рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб. |
| *2.* | *Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар* | | |
| 2.1 | 1А-6А | дәүләт хезмәте өчен җыем түләү факты турында белешмәләр | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – документның күчермәсе; почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк; гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан-рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб. Акт биргән өчен җыем түләнүен тикшерү ГИС ГМП системасын куллану юлы белән гамәлгә ашырыла. |
| 2.3 | 2А, 5А | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – документның күчермәсе; почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк; гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб<br>Белешмәләр Россия Федераль салым хезмәте идарәсе тарафыннан бирелә; |
| 2.4 | 3А, 4А | шәхси эшкуар турында Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Идарә бүлегенә шәхсән тапшырганда – документның күчермәсе;<br>почта/электрон почта аша җибәргәндә – күчермә/сканүрнәк;<br>гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Республика порталы ярдәмендә җибәргәндә: киңәйтелгән документның скан-рәвешен үз эченә алган файл *.PDF, *.ZIP, *.RAR, файлның максималь рөхсәт ителгән күләме — 50 Мб<br>Белешмәләр Россия Федераль салым хезмәте идарәсе тарафыннан бирелә; |

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Мөрәҗәгать итүче билгесе идентификаторы | Нигезләр исемлеге |
|---|---|---|
| *1.* | *Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге* | |
| 1.1 | 1А-5А | гариза формасында мәҗбүри кырларның дөрес тутырылмавы; |
| 1.2 | 1А-5А | гаризаның һәм электрон формадагы башка документларның законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган булуы; |
| 1.3 | 1А-5А | электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы; |
| 1.4. | 1А-5А | әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән бер яисә берничә документның булмавы. |
| *2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.* | | |
| *3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге* | | |
| 2.1. | 1А-6А | дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен җыем түләү турында мәгълүмат булмавы; |
| 2.2. | 1А-6А | тапшырылган (алынган) документларда (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булуы; |
| 2.3. | 1А-6А | үзйөрешле техниканың һәм җайланманың тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәве; |
| 2.4. | 1А-6А | эксплуатацияләү буенча гарантия срогының тәмамлануы. |

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

**Сатылган яисә ремонтланган техниканың тиешле сыйфатта булмавы уңаеннан үзйөрешле машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза**

Кая ________________________________________________________________

(үзйөрешле машиналар ның һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торшышы һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының тулы атамасы (алга таба – дәүләт техник күзәтчелек органы))

Кемнән

________________________________________________________________

(юридик затның исеме, юридик адресы яисә физик затның фамилиясе, инициаллары, яшәү урыны адресы)

Үзйөрешле техниканың һәм җайланмаларның эшләмәү сәбәпләрен карау буенча комиссиядә катнашуыгызны сорыйм. : «____» ____________ 20___ел.
адресы: ____________________________________________________________
Машинаның (җайланманың) исеме һәм маркасы___________________________
Җитештерүче предприятие (сервис оешмасы)___________________________
Завод номеры __________________________, эксплуатацияләүнең гарантияле вакыты___________ ай.
Кемгә карый ______________________________________________________

(юридик затның исеме, юридик адресы яисә физик затның ФИА,

________________________________________________________________

яшәү урыны адресы)

Саткан оешма (җитештерүче предприятие) яисә ремонтлаган сервис оешмасы ________________________________

(гарантия бирүченең исеме, аның почта адресы)

________________________________________________________________

Чыгарылу (ремонт) датасы) «____»_______________20__ел.
Үзйөрешле техниканы һәм җайланмаларны файдалануга тапшыру датасы «__»______20___ел.
Эшләми башлау датасы «____»___________20___ел.

Үзйөрешле техника һәм җайланмалар файдалануга тапшырылганнан бирле узган вакыт

______________________________________________________________________

(айлар, көннәр, мото-сәгатьләр, км юл)

Эшләү шартлары

_________________________________________________________________

(үзйөрешле техниканың һәм җайланманың төрләре һәм эш шартлары)

Баш тарту чагылдырылган:______________________________________________________

(баш тартуның тышкы чагылышын тасвирлау)

______________________________________________________________________

Эшләүдән баш тарту сәбәпләрен комиссия тарафыннан карау вакытын һәм датасын килештерү өчен үзйөрешле техника һәм җайланма хуҗасы белән элемтә реквизитлары:

__________________________________________________________________________

(телефон, e-mail)

| | |
|---|---|
| ________________________<br>(имза)<br><br>Мөһер урыны (булган очракта) | ______________________________<br>(юр. зат җитәкчесенең фамилиясе, инициаллары,<br>шәхси эшкуар, физик зат) |

«_____» ________________20___ел.

Мөрәҗәгать итүчедән кабул ителде:_________________________________________

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

_____________________________________________________

___________________ ______________________ __________________________

(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

## ДӘГЪВАЛАРНЫ КАРАУ АКТЫ

Актны төзү урыны___________________________________________________
(хуҗасының, физик яисә юридик затның адресы)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
Төзелү датасы______________

Комиссия тарафыннан түбәндәгеләр составында төзелде:
Тәэмин итүче (җитештерүче, сервис предприятиесе) вәкиле_____________
______________________________________________________________________
(фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы)
______________________________________________________________________
дәүләт техник күзәтчелек вәкиле____________________________________________
(фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы)
хуҗасының вәкиле________________________________________________
(фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы)
үзйөрешле техникага һәм җиһазларга ____________________________________
(исеме, маркасы)
чыгарылу (ремонт) датасы _________________ завод №___________________
файдалануга тапшырылган_________________ двигатель № __________________
файдалануга тапшырылганнан бирле эшләү вакыты___________ сәгать (көн)
эшләү шартлары
_____________________________________________________________
(эш төрен күрсәтергә)

**Үзйөрешле техниканы һәм җайланманы карау нәтиҗәләренең тасвирламасы**

Эшләмәүнең (төзексезлекнең) тышкы чагылышы______________________________
______________________________________________________________________
Эшләмәү (төзексезлек) характеристикасы___________________________________
______________________________________________________________________
Эшләмәү (төзексезлек) сәбәпләре___________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**Тикшерү барышында ачыкланды:**

| т/с | Машина һәм (яисә) җайланманың эшләмәү сәбәбе | Ачыклау турында тамга |
|---|---|---|

| | | | (әйе/юк) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | | 3 |
| 1 | Эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу | | |
| 2 | Җитештерү сәбәбе | сатучы гаебе | |
| | | тәэмин итүче гаебе | |
| 3 | Җитештерүче завод гаебе | | |
| 4 | Сатучы (тәэмин итүче) һәм дәүләт техник күзәтчелек вәкилләре килгәнче хуҗасы тарафыннан үзйөрешле техниканы һәм җиһазларны сүтү һәм ремонтлау аркасында эшләмәү сәбәбе билгеләнмәде | | |
| 5 | Үзйөрешле техника һәм җиһазлар ЗИПтан запас частьләр (запас частьләр, инструментлар, кирәк-яраклар) яисә эксплуатация буенча инструкциядә каралган көйләү ярдәмендә торгызылырга мөмкин булган. | | |
| 6 | Үзйөрешле техника һәм җиһазлар төзек, эшләмәү очрагы расланмады | | |

Гаепле якны тану турында нәтиҗә_______________________________________

___________________________________________________________________________

Кирәкле узеллар (агрегатлар, детальләр) исемлеге ___________________________

исеме, каталог буенча №

___________________________________________________________________________

транспорт чыгымнары _______________ сум, башка чыгымнар _____________ сум

Өстәмә чыгымнарны исәпкә алып, чыгымнарның гомуми суммасы____________ сум

Эшләмәүне, төзексезлекне бетерү чыгымнарын_____________

___________________________________________________________________________.

Предприятие вәкиле
(тәэмин итүче, сервис оешмасы)

______________________________
(имза)
«____»______________ 20___ ел.

Хуҗасы (аның вәкиле)

______________________________
(имза)
«____»______________ 20___ел.

Дәүләт техник күзәтчелек вәкиле

______________________________
(имза)
«____»________________ 20___ ел.

Комиссиянең башка әгъзалары

______________________________
(имза)
«____»______________ 20___ел.

Ремонт эшләре төгәлләнде
Ремонтланган үзйөрешле техника һәм
җайланмалар хуҗасына кайтарылды

«_____»____________ 20___ ел.

«_____»____________ 20___ ел.

Предприятие вәкиле
(тәэмин итүче, сервис оешмасы)

_______________________________
(имза)

Хуҗасының вәкиле

_______________________________
(имза)

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Кемгә
(оешманың тулы исеме – юридик затлар, физик затлар)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

Датасы____________ №____________

(*мөрәҗәгать итүче*) ________________________ ___________№___________

мөрәҗәгатен караганда, Сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмау сәбәпле, күзәтчелектәге машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау буенча комиссияләрдә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.12.1 пункты нигезендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде (*баш тарту өчен нигез*): ________________________________________________________.

Баш тарту өчен мотивлаштырылган нигезләү:__________________________.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ______________________________________
(*баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә*).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, яңадан мөрәҗәгать итү өчен каршылык булып тормый.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

(карар кабул ителә торган органда вәкаләтле затның вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Сатылган яки төзәтелгән техниканың тиешле сыйфатта булмавына бәйле рәвештә күзәтчелектәге машиналарның һәм җайланмаларның хуҗалары дәгъваларын карау комиссияләрендә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Кемгә
(оешманың тулы исеме – юридик затлар, ШЭ өчен)

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

Дата____________ №____________

(Мөрәҗәгать итүче) _______________________ ___________№___________ мөрәҗәгатен караганда, Сатылган яки ремонтланган техниканың сыйфаты тиешенчә булмау сәбәпле, күзәтчелектәге машиналар һәм җайланмалар хуҗаларының дәгъваларын карау буенча комиссияләрдә катнашу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.12.3 пункты нигезендә, (баш тарту өчен нигез): _________________________________________________________.

Баш тарту өчен мотивлаштырылган нигезләү: _________________________.

Өстәмә мәгълүмат бирәбез: __________________________________________
(баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук булган очракта башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабат мөрәҗәгать итүгә комачаулый алмый.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

*(карар кабул ителә торган органда вәкаләтле затның вазыйфасы* *(имзасы)* *(фамилиясе, инициаллары)*